КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 12 апрель г.Казань № 282

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2017 – 2020 елларга Татарстан Республикасын комплекслы социаль-икътисадый үстерүне тәэмин итү мониторингы өчен кирәкле күрсәткечләрнең мәгънәләрен раслау турында» 2012 ел, 4 май, 351 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2017 – 2020 елларга Татарстан Республикасын комплекслы социаль-икътисадый үстерүне тәэмин итү мониторингы өчен кирәкле күрсәткечләрнең мәгънәләрен раслау турында» 2012 ел, 4 май, 351 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 2 июнь, 373 нче; 2015 ел, 24 апрель, 283 нче; 2016 ел, 31 май, 363 нче; 2017 ел, 21 апрель, 233 нче; 2018 ел, 13 апрель, 244 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карарның исемендә һәм 1 пунктында «2017 – 2020 елларга» сүзләрен «2018 – 2021 елларга» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган 2018 – 2021 елларга Татарстан Республикасын комплекслы социаль-икътисадый үстерүне тәэмин итү мониторингы өчен кирәкле күрсәткечләрнең мәгънәләрен яңа редакциядә бәян итәргә (карарга теркәләләр).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин